**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 41 «21» октябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмә хакында» 2021 елның 30 ноябрендәге 48 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (21.02.2022 №12, 07.06.2022 №28, 29.09.2022 №44, 28.06.2023 №32, 27.10.2023 №52, 30.05.2024 №21 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә (ред. 08.08.2024),

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмә хакында» 2021 елның 30 ноябрендәге 48 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (21.02.2022 №12, 07.06.2022 №28, 29.09.2022 №44, 28.06.2023 №32, 27.10.2023 №52, 30.05.2024 №21 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 4.3. бүлекнең 4.3.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3.5. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул итәлергә тиеш түгел.».

1.2. 4.5. бүлекнең 4.5.9. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.9. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-6 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми.».

1.3. 4.7. бүлекнең 4.7.4. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.7.4. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә тикшерү үткәрелгән очраклар керми.».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Азнакай районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис А.Л. Севостьянов